**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «Об учреждении Государственных премий Республики Татарстан в области науки и техники»**

В целях совершенствования деятельности по присуждению Государственных премий Республики Татарстан в области науки и техники **постановляю:**

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 16 апреля 1993 года № УП-206 «Об учреждении Государственных премий Республики Татарстан в области науки и техники» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 9 марта 1999 года № УП-147, от 13 декабря 2000 года № УП-979, от 6 апреля 2001 года № УП-265, от 24 декабря 2005 года № УП-514, от 4 апреля 2006 года № УП-129, от 12 января 2007 года № УП-4, от 20 марта 2008 года № УП-120, от 16 декабря 2013 года № УП-1232 и от 9 декабря 2014 года № УП-1120) следующие изменения:

а) в пункте 1 слово «восемь» заменить словом «пять», слово «пятисот» заменить словом «восьмисот»;

б) в пункте 5 слова «на указанную Комиссию» заменить словами «на Комиссию при Президенте Республики Татарстан по Государственным премиям Республики Татарстан в области науки и техники»;

в) в пункте 6 слова «указанной Комиссии» заменить словами «Комиссии при Президенте Республики Татарстан по Государственным премиям Республики Татарстан в области науки и техники»;

г) в пункте 7 слова «Комиссии по Государственным премиям Республики Татарстан в области науки и техники» заменить словами «Комиссии при Президенте Республики Татарстан по Государственным премиям Республики Татарстан в области науки и техники»;

д) в Положении о Государственных премиях Республики Татарстан в области науки и техники:

в пункте 4 слова «повторно не присуждаются» заменить словами «могут присуждаться повторно не ранее чем через пять лет после предыдущего присуждения»;

пункт 5 дополнить абзацем следующего содержания:

«В случае смерти лица после его выдвижения на соискание Государственной премии Республики Татарстан в области науки и техники допускается присуждение премии посмертно. Диплом, Почетный знак и удостоверение награжденного посмертно или умершего лауреата передаются или оставляются его семье как память, а денежное вознаграждение передается по наследству в порядке, установленном законодательством Российской Федерации.»;

в абзаце первом пункта 7 слова «в количестве до 8 премий в размере пятисот тысяч рублей каждая» заменить словами «в количестве до пяти премий в размере восьмисот тысяч рублей каждая».

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань,Кремль
01 февраля 2017 года
№ УП-88

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләрен гамәлгә кую турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләрен бирү буенча эшчәнлекне камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләрен гамәлгә кую турында» 1993 елның 16 апрелендәге ПУ-206 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 1999 елның 9 мартындагы ПУ-147 номерлы, 2000 елның 13 декабрендәге ПУ-979 номерлы, 2001 елның 6 апрелендәге ПУ-265 номерлы, 2005 елның 24 декабрендәге ПУ-514 номерлы, 2006 елның 4 апрелендәге ПУ-129 номерлы, 2007 елның 12 гыйнварындагы ПУ-4 номерлы, 2008 елның 20 мартындагы ПУ-120 номерлы, 2013 елның 16 декабрендәге ПУ-1232 номерлы һәм 2014 елның 9 декабрендәге ПУ-1120 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 пунктта «сигез» сүзен «биш» сүзенә, «биш йөз» сүзен «сигез йөз» сүзенә алмаштырырга;

б) 5 пунктта «әлеге Комиссиягә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләре буенча комиссиягә» сүзләренә алмаштырырга;

в) 6 пунктта «әлеге Комиссия» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләре буенча комиссия» сүзләренә алмаштырырга;

г) 7 пунктта «Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләре буенча комиссия» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләре буенча комиссия» сүзләренә алмаштырырга;

д) Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләре турында нигезләмәдә:

4 пунктта «кабаттан бирелми» сүзләрен «алдагы бүләкләнүдән соң биш ел узгач кына кабаттан бирелә ала» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премиясе белән бүләкләнүгә тәкъдим ителгән зат вафат булган очракта, премия аңа вафатыннан соң тапшырылырга мөмкин. Вафатыннан соң бүләкләнгән яисә вафат булган лауреатның Дипломы, Мактау билгесе һәм таныклыгы гаиләсенә истәлек итеп саклау өчен бирелә һәм аларда калдырыла, ә акчалата бүләк Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә мирас буенча тапшырыла.»;

7 пунктның беренче абзацында «һәрберсе биш йөз сум күләмендә 8 премиягә кадәр» сүзләрен «һәрберсе сигез йөз сум күләмендә биш премиягә кадәр» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан,Кремль
2017 ел, 01 февраль
№ ПУ-88